ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

«30» декабрь 2019 ел № 503

Әгерҗе муниципаль районы
«Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең
яңа штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Һөнәри стандартларны эшләү һәм раслау кагыйдәләре турында» 2013 елның 22 гыйнварындагы 23 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Һөнәри стандартларны эшләү, раслау һәм куллану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 сентябрендәге 970 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының ««Хезмәтне саклау өлкәсендә белгеч» һөнәри стандартын раслау турында» 2014 елның 04 августындагы 524н боерыгы нигезендә, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының ««Персонал белән идарә итү буенча белгеч» һөнәри стандартын раслау турында» 2015 елның 6 октябрендәге 691н номерлы боерыгы һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең яңа штат расписаниесен раслау турында» 2019 елның 3 июнендәге 218 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 3 июнендәге 218 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең яңа штат расписаниесенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге берәмлекләрне штат расписаниесеннән чыгарырга:

-«Хезмәтне саклау буенча инженер»;

-«Кадрлар буенча инспектор»

1.2. Түбәндәге берәмлекләрне штат расписаниесенә кертергә:

- Хезмәтне саклау буенча белгеч;

- Персонал буенча белгеч.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Баженовага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе **А.С. Авдеев**